ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 492-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 492-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 19 октябре
№ 2164-VI ДС

Проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

**1 статья**

«2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 2022 елның 23 ноябрендәге 83-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2022, №90 (1 өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда:
а) 1 өлештә:
1 пунктта «70 598 941,5» санын «70 471 572,4» санына, «60 186 154,4» санын «60 329 663,7» санына, «9 384 576,2» санын «9 476 469,9» санына алмаштырырга;
2 пунктта «70 598 941,5» санын «72 148 109,2» санына алмаштырырга;
түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:
«3) Фонд бюджеты кытлыгын 1 676 536,8 сум итеп»;
б) түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәргә:
«3. 2023 елга Фонд бюджеты кытлыгын эчке финанслау чыганакларын әлеге Законга 5 нче кушымта нигезендә расларга.»;

2) 6 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1. 2023 елга Фондның нормалаштырылган иминият запасы акчалары күләмен 8 659 763,6 мең сум, 2024 елга 8 143 806,9 мең сум, 2025 елга 8 550 206,2 мең сум итеп расларга.»;

3) 7 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«**7 статья.**
Татарстан Республикасы территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын гамәлгә ашыруда катнаша торган иминләштерүче медицина оешмалары өчен мәҗбүри медицина иминияте буенча эш алып баруга чыгымнар

нормативын мәҗбүри медицина иминиятен финанс белән тәэмин итүнең җан башына дифференциацияләп исәпләнгән нормативлары буенча 2023 елның гыйнварында һәм аннан соң килгән чорларда иминләштерүче медицина оешмасына кергән акчалар суммасыннан 0,95 процент һәм 2022 елның декабрендә дифференциацияләп исәпләнгән нормативлары буенча 2023 елда иминләштерүче медицина оешмасына кергән акчалар суммасыннан 1,0 процент күләмендә билгеләргә.»;

4) түбәндәге эчтәлекле 8[1]. статьясын өстәргә:

«**8[1] статья.**

Фонд бюджетының агымдагы финанс елы башына файдаланылмый калган, бюджет турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә кире кайтарылырга тиеш булмаган акчалары, әлеге Законга үзгәрешләр кертмичә, Фондның җыелма бюджет язуына тиешенчә үзгәрешләр кертеп, Фондның нормалаштырылган иминият запасы акчалары исәбеннән агымдагы финанс елында Татарстан Республикасында Территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасы үтәлешен, квалификация күтәрү программалары буенча медицина хезмәткәрләренә өстәмә һөнәр белеме бирүне оештыру, шулай ук медицина җиһазлары сатып алу һәм ремонтлау чараларын, иминләштерелгән затларга мәҗбүри медицина иминияте полисы бирелгән Россия Федерациясе субъекты территориясеннән читтә күрсәтелгән медицина ярдәменә түләүне финанс белән тәэмин итүгә җибәрелә дип билгеләргә.»;

5) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына
Татарстан Республикасы Территориаль
мәҗбүри медицина иминияте фонды
бюджеты турында» Татарстан
Республикасы Законына
1 нче кушымта

**2023 елга Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты керемнәре**

)

| Бюджет классификациясе кодлары | Керем исеме | Суммасы |
|---|---|---|
| 000 1 00 00000 00 0000 000 | Салым керемнәре һәм салым булмаган керемнәр | 125 893,0 |
| 395 1 13 00000 00 0000 000 | Түләүле хезмәт күрсәтүләрдән һәм дәүләт чыгымнарын компенсацияләүдән керемнәр | 74 513,2 |
| 395 1 13 02000 00 0000 130 | Дәүләт чыгымнарын компенсацияләүдән керемнәр | 74 513,2 |

| | | |
|---|---|---|
| 395 1 13 02990 00 0000 130 | Дәүләт чыгымнарын компенсацияләүдән башка керемнәр | 74 513,2 |
| 395 1 13 02999 09 0000 130 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетлары чыгымнарын компенсацияләүдән бүтән керемнәр | 74 513,2 |
| 395 1 16 00000 00 0000 000 | Штрафлар, санкцияләр, зыянны каплау | 51 379,8 |
| 395 1 16 07000 00 0000 140 | Дәүләт (муниципаль) органы, бюджеттан тыш дәүләт фонды белән идарә итү органы, казна учреждениесе, Россия Федерациясе Үзәк банкы, Россия Федерациясе исеменнән эш итүче бүтән оешма алдындагы йөкләмәләрне үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта закон яисә килешү нигезендә түләнгән штрафлар, неустойкалар, пенялар | 10 816,9 |
| 395 1 16 07010 00 0000 140 | Кайтартучы (подрядчы, башкаручы) дәүләт (муниципаль) контракты белән күздә тотылган йөкләмәләрне үтәүне кичектереп торган очракта түләнгән штрафлар, неустойкалар, пенялар | 2,0 |
| 395 1 16 07 010 09 0000 140 | Кайтартучы (подрядчы, башкаручы) территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды белән төзелгән дәүләт контрактында күздә тотылган йөкләмәләрне үтәүне кичектереп торган очракта түләнгән штрафлар, неустойкалар, пенялар | 2,0 |
| 395 1 16 07090 00 0000 140 | Дәүләт (муниципаль) органы, казна учреждениесе, Россия Федерациясе Үзәк банкы, дәүләт корпорациясе алдындагы йөкләмәләрне үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта закон яисә килешү нигезендә түләнгән башка штрафлар, неустойкалар, пенялар | 10 814,9 |

| | | |
|---|---|---|
| 395 1 16 07090 09 0000 140 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды алдындагы йөкләмәләрне үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта закон яисә шартнамә нигезендә түләнгән башка штрафлар, неустойкалар, пенялар | 10 814,9 |
| 395 1 16 10000 00 0000 140 | Китерелгән зыянны (зарарны) каплау максатларында түләүләр | 40 562,9 |
| 395 1 16 10100 00 0000 140 | Бюджет акчаларыннан законсыз яисә максатка яраксыз файдалану аркасында китерелгән зыянны каплауга салына торган акчалата түләтүләр | 35 861,3 |
| 395 1 16 10100 09 0000 140 | Бюджет акчаларын законсыз яисә максатка яраксыз файдалану аркасында китерелгән зыянны каплауга салына торган акчалата түләтүләр (территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетлары өлешендә) | 35 861,3 |
| 395 1 16 10110 00 0000 140 | Файда күрүчеләр бюджеттан тыш дәүләт фондлары бюджетлары акчаларын алучылар булган иминият очраклары килеп чыкканда зыянны каплау һәм алар карамагында һәм файдалануында булган федераль милеккә китерелгән зыянны башкача каплау | 3 969,1 |
| 395 1 16 10119 09 0000 140 | Иминләштерелгән затның сәламәтлегенә зыян китергән өчен җаваплы затларга медицина ярдәме күрсәтүгә чыгымнарны каплау максатларында территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды керткән дәгъвалар буенча түләүләр | 3 969,1 |
| 395 1 16 10120 00 0000 140 | 2020 елның 1 гыйнварына кадәр барлыкка килгән бурычларны каплау исәбенә керә торган акчалата түләтүләрдән (штрафлардан) 2019 елда гамәлдә булган нормативлар буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына күчерелергә тиешле керемнәр | 732,5 |

| | | |
|---|---|---|
| 395 1 16 10127 01 0000 140 | 2020 елның 1 гыйнварына кадәр барлыкка килгән бурычларны каплау исәбенә керә торган акчалата түләтүләрдән (штрафлардан) 2019 елда гамәлдә булган нормативлар буенча территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына күчерелергә тиешле керемнәр | 732,5 |
| 395 2 00 00000 00 0000 000 | Кире кайтарылмый торган кертемнәр | 70 345 679,4 |
| 395 2 02 00000 00 0000 000 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан кире кайтарылмый торган кертемнәр | 70 834 344,5 |
| 395 2 02 50000 00 0000 150 | Бюджеттан тыш дәүләт фондлары бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар | 63 118 933,8 |
| 395 2 02 50203 09 0000 150 | Медицина ярдәме күрсәтүнең мәҗбүри медицина иминияте база программасы белән билгеләнмәгән өстәмә төрләрен һәм шартларын финанс белән тәэмин итүгә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар | 1 761 059,2 |
| 395 2 02 55093 09 0000 150 | Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә мәҗбүри медицина иминиятен оештыруны финанс белән тәэмин итүгә территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларына субвенцияләр | 60 186 154,4 |
| 395 2 02 55257 09 0000 150 | Медицина оешмаларының табиблар һәм урта медицина персоналы хезмәте өчен түләү чыгымнарын финанслашу максатларында территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар | 141 909,2 |

| | | |
|---|---|---|
| 395 2 02 55258 09 0000 150 | Халыкка диспансеризация һәм профилактик медицина тикшерүләрен уздыру барышында онкология авыруларын ачыклаган өчен медицина хезмәткәрләренә стимуллаштыру характерындагы акчалата түләүләрне гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар | 1 600,1 |
| 395 2 02 59999 00 0000 150 | Бюджеттан тыш дәүләт фондлары бюджетларына тапшырыла торган башка бюджетара трансфертлар | 1 028 210,9 |
| 395 2 02 59999 09 0000 150 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларына тапшырыла торган башка бюджетара трансфертлар | 1 028 210,9 |
| 395 2 02 90000 00 0000 150 | Бюджет системасының башка бюджетларыннан бирелгән кире кайтарылмый торган бүтән кертемнәр | 7 715 410,7 |
| 395 2 02 90020 00 0000 150 | Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан бирелгән кире кайтарылмый торган башка кертемнәр | 7 715 410,7 |
| 395 2 02 90029 09 0000 150 | Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларына бирелгән кире кайтарылмый торган башка кертемнәр | 7 715 410,7 |
| 395 2 18 00000 00 0000 000 | Узган еллардан калган максатчан билгеләнештәге субсидияләрне, субвенцияләрне һәм башка бюджетара трансфертларны кире кайтарудан Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары керемнәре | 1 599,6 |

| | | |
|---|---|---|
| 395 2 18 00000 00 0000 150 | Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары тарафыннан узган еллардан калган максатчан билгеләнештәге субсидияләрне, субвенцияләрне һәм башка бюджетара трансфертларны кире кайтарудан, шулай ук оешмалар тарафыннан узган еллардан калган субсидияләрне кире кайтарудан Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары керемнәре | 1 599,6 |
| 395 2 18 00000 09 0000 150 | Узган еллардан калган максатчан билгеләнештәге субсидияләрне, субвенцияләрне һәм башка бюджетара трансфертларны кире кайтарудан территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетлары керемнәре | 1 599,6 |
| 395 2 18 45136 09 0000 150 | Медицина хезмәткәрләренә бер тапкыр бирелә торган түләүләрне гамәлгә ашыруга узган еллардан калган бюджетара трансфертларны кире кайтарудан территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты керемнәре | 190,1 |
| 395 2 18 73000 09 0000 150 | Узган еллардан калган максатчан билгеләнештәге субсидияләрне, субвенцияләрне һәм башка бюджетара трансфертларны кире кайтарудан территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетлары керемнәре | 1 409,5 |
| 395 2 19 00000 00 0000 000 | Узган еллардан калган максатчан билгеләнештәге субсидияләрне, субвенцияләрне һәм башка бюджетара трансфертларны кире кайтару | - 490 264,7 |
| 395 2 19 00000 09 0000 150 | Узган еллардан калган максатчан билгеләнештәге субсидияләрне, субвенцияләрне һәм башка бюджетара трансфертларны территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларыннан кире кайтару | - 490 264,7 |

| | | |
|---|---|---|
| 395 2 19 55093 09 0000 150 | Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә мәҗбүри медицина иминиятен оештыруны финанс белән тәэмин итүгә узган еллардан калган субвенцияләрне территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларыннан Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына кире кайтару | - 58 181,5 |
| 395 2 19 55136 09 0000 150 | Медицина хезмәткәрләренә бер тапкыр бирелә торган түләүләрне гамәлгә ашыруга узган еллардан калган бюджетара трансфертларны территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларыннан Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына кире кайтару | - 190,1 |
| 395 2 19 55231 09 0000 150 | Яңа коронавирус инфекциясе белән авыручы һәм (яисә) авырый дип шикләнелүче мәҗбүри медицина иминияте буенча иминләштерелгән затларга территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын гамәлгә ашыру кысаларында медицина ярдәме күрсәтүне өстәмә финанс белән тәэмин итүгә узган еллардан калган бюджетара трансфертларны территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларыннан кире кайтару | -226,5 |
| 395 2 19 55257 09 0000 150 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондының нормалаштырылган иминият запасын формалаштыруны финанс белән тәэмин итүгә узган еллардан калган бюджетара трансфертларны территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларыннан Федераль мәҗбүри медицина иминияте | - 367 816,4 |

| | | |
|---|---|---|
| | фонды бюджетына кире кайтару | |
| 395 2 19 55258 09 0000 150 | Халыкка диспансеризация һәм профилактик медицина тикшерүләрен уздыру барышында онкология авыруларын ачыклаган өчен медицина хезмәткәрләренә кызыксындыру характерындагы акчалата түләүләрне гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә узган еллардан калган бюджетара трансфертларны территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларыннан Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына кире кайтару | - 1 454,0 |
| 395 2 19 55849 09 0000 150 | Мәҗбүри медицина иминияте буенча иминләштерелгән, шул исәптән яңа коронавирус инфекциясе (COVID-19) белән авыручы һәм (яисә) авырый дип шикләнелүче затларга Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды акчалары исәбеннән территориаль мәҗбүри медицина иминияте программаларын гамәлгә ашыру кысаларында медицина ярдәме күрсәтүне өстәмә финанс белән тәэмин итүгә тиешле территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына бюджетара трансфертлар бирү буенча Россия Федерациясе субъектларының һәм Байконур шәһәренең чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү максатларында калган башка бюджетара трансфертларны территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларыннан кире кайтару | -311,1 |

| | | |
|---|---|---|
| 395 2 19 71030 09 0000 150 | Узган еллардан калган максатчан билгеләнештәге башка субсидияләрне, субвенцияләрне һәм башка бюджетара трансфертларны территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларыннан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына кире кайтару | - 61 748,4 |
| 395 2 19 73000 09 0000 150 | Узган еллардан калган максатчан билгеләнештәге субсидияләрне, субвенцияләрне һәм башка бюджетара трансфертларны территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларыннан территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларына кире кайтару | - 336,7 |
| | Керемнәр, барлыгы | 70 471 572,4»; |

6) 3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына
Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри
медицина иминияте фонды бюджеты турында»
Татарстан Республикасы Законына 3 нче кушымта

2023 елга Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлү

(мең сумнарда)

| Исеме | Бюджет классификациясе кодлары | | | | | Суммасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Мин | Рз | ПР | ЦСР | ВР | |
| Гомумдәүләт мәсьәләләре | 395 | 01 | 00 | | | 340 989,9 |
| Башка гомумдәүләт мәсьәләләре | 395 | 01 | 13 | | | 340 989,9 |
| Россия Федерациясе бюджеттан тыш дәүләт фондларының идарә органнары эшчәнлегенең | 395 | 01 | 13 | 73 0 00 0000 0 | | 340 989,9 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| программага кертелмәгән юнәлешләре | | | | | | |
| Россия Федерациясе бюджеттан тыш дәүләт фондлары аппаратлары тарафыннан функцияләр башкару | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 0000 0 | | 340 989,9 |
| Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә мәҗбүри медицина иминиятен оештыруны финанс белән тәэмин итү | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 5093 0 | | 312 239,1 |
| Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды аппараты тарафыннан функцияләр башкаруга чыгымнар өлешендә Татарстан Республикасы территориясендә мәҗбүри медицина иминиятен оештыруны финанс белән тәэмин итү | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 5093 4 | | 312 239,1 |
| Дәүләт (муниципаль) органнары, казна учреждениеләре, бюджеттан тыш дәүләт фондлары белән идарә итү органнары тарафыннан функцияләр башкаруны тәэмин итү максатларында персоналга түләү чыгымнары | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 5093 4 | 100 | 213 939,3 |
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 5093 4 | 200 | 93 691,8 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка башка түләүләр | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 5093 4 | 300 | 60,0 |
| Башка бюджет ассигнованиеләре | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 5093 4 | 800 | 4 548,0 |
| Башка түләүләр | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 9235 0 | | 28 750,8 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Дәүләт (муниципаль) органнары, казна учреждениеләре, бюджеттан тыш дәүләт фондлары белән идарә итү органнары функцияләрен башкаруны тәэмин итү максатларында персоналга түләү чыгымнары | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 9235 0 | 100 | 28 750,8 |
| Сәламәтлек саклау | 395 | 09 | 00 | | | 71 664 985,7 |
| Ашыгыч медицина ярдәме | 395 | 09 | 04 | | | 151 434,0 |
| «Татарстан Республикасында сәламәтлек саклауны үстерү» дәүләт программасы | 395 | 09 | 04 | 01 0 00 0000 0 | | 151 434,0 |
| «Махсуслаштырылган, югары технологиялене дә кертеп, медицина ярдәме, ашыгыч, шул исәптән ашыгыч махсуслаштырылган, медицина ярдәме күрсәтүне, медицина эвакуациясен камилләштерү» ярдәмче программасы | 395 | 09 | 04 | 01 2 00 0000 0 | | 151 434,0 |
| Медицина оешмаларын мәҗбүри медицина иминияте системасы аша күбесенчә бер каналлы финанслауны гамәлгә ашыру (югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүдән тыш) | 395 | 09 | 04 | 01 2 12 0000 0 | | 66 857,4 |
| Медицина оешмаларын мәҗбүри медицина иминияте системасы аша күбесенчә бер каналлы финанслауны гамәлгә ашыру | 395 | 09 | 04 | 01 2 12 0519 0 | | 66 857,4 |
| Махсуслаштырылган, ашыгыч, шул исәптән ашыгыч махсуслаштырылган, медицина ярдәме күрсәтүне, медицина эвакуациясен мәҗбүри медицина иминияте системасы аша күбесенчә бер каналлы финанслауны гамәлгә ашыру | 395 | 09 | 04 | 01 2 12 0519 3 | | 66 857,4 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка башка түләүләр | 395 | 09 | 04 | 01 2 12 0519 3 | 300 | 66 857,4 |
| «Башлангыч медицина-санитария ярдәме күрсәтү системасын үстерү» федераль проекты | 395 | 09 | 04 | 01 2 N1 0000 0 | | 84 576,6 |
| Медицина ярдәме күрсәтү максатларында авиация эшләре сатып алуны тәэмин итүгә финанслашу чыгымнары | 395 | 09 | 04 | 01 2 N1 5554 0 | | 84 576,6 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка башка түләүләр | 395 | 09 | 04 | 01 2 N1 5554 0 | 300 | 84 576,6 |
| Сәламәтлек саклау өлкәсендә башка мәсьәләләр | 395 | 09 | 09 | | | 71 513 551,7 |
| «Татарстан Республикасында сәламәтлек саклауны үстерү» дәүләт программасы | 395 | 09 | 09 | 01 0 00 0000 0 | | 71 513 551,7 |
| «Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру системасын камилләштерү» ярдәмче программасы | 395 | 09 | 09 | 01 Б 00 0000 0 | | 62 260 942,2 |
| Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру системасын камилләштерү | 395 | 09 | 09 | 01 Б 01 0000 0 | | 62 260 942,2 |
| Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә мәҗбүри медицина иминиятен оештыруны финанс белән тәэмин итү | 395 | 09 | 09 | 01 Б 01 5093 0 | | 60 891 948,0 |
| «Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру системасын камилләштерү» ярдәмче программасы кысаларында медицина ярдәменә түләү өлешендә Татарстан Республикасы территориясендә мәҗбүри медицина иминиятен оештыруны финанс белән тәэмин итү | 395 | 09 | 09 | 01 Б 01 5093 1 | | 59 482 229,8 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка башка түләүләр | 395 | 09 | 09 | 01 Б 01 5093 1 | 300 | 59 482 229,8 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру системасын камилләштерү» ярдәмче программасы кысаларында Татарстан Республикасында иминләштерелгән һәм медицина ярдәмен иминләштерү территориясеннән читтә алган затларга медицина ярдәменә түләү өлешендә Татарстан Республикасы территориясендә мәҗбүри медицина иминиятен оештыруны финанс белән тәэмин итү | 395 | 09 | 09 | 01 Б 01 5093 2 | | 1 409 718,2 |
| Бюджетара трансфертлар | 395 | 09 | 09 | 01 Б 01 5093 2 | 500 | 1 409 718,2 |
| Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондының нормалаштырылган иминият запасы акчалары исәбеннән табиблар һәм урта медицина персоналы хезмәте өчен түләүгә медицина оешмаларына финанслашу чыгымнары | 395 | 09 | 09 | 01 Б 01 5257 0 | | 141 909,2 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка башка түләүләр | 395 | 09 | 09 | 01 Б 01 5257 0 | 300 | 141 909,2 |
| Диспансеризация һәм профилактик медицина тикшерүләрен уздыру барышында онкология авыруларын ачыклаган өчен медицина хезмәткәрләренә стимуллаштыру характерындагы акчалата түләүләрне гамәлгә ашыру | 395 | 09 | 09 | 01 Б 01 5258 0 | | 1 600,1 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка башка түләүләр | 395 | 09 | 09 | 01 Б 01 5258 0 | 300 | 1 600,1 |
| Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондының нормалаштырылган иминият запасы | 395 | 09 | 09 | 01 Б 01 0529 0 | | 154 670,1 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| акчалары исәбеннән медицина хезмәткәрләренә квалификация күтәрү программалары буенча өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру, шулай ук медицина җиһазлары сатып алу һәм ремонтлау чараларын финанс белән тәэмин итү | | | | | | |
| Бюджет учреждениеләренә, автоном учреждениеләргә һәм коммерциячел булмаган башка оешмаларга субсидияләр бирү | 395 | 09 | 09 | 01 Б 01 0529 0 | 600 | 154 670,1 |
| Россия Федерациясенең башка субъектлары территориясендә иминләштерелгән затларга Татарстан Республикасы медицина оешмалары тарафыннан күрсәтелгән медицина ярдәме | 395 | 09 | 09 | 01 Б 01 0539 0 | | 1 070 814,8 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка башка түләүләр | 395 | 09 | 09 | 01 Б 01 0539 0 | 300 | 1 070 814,8 |
| «Махсуслаштырылган, югары технологияләне дә кертеп, медицина ярдәме, ашыгыч, шул исәптән ашыгыч махсуслаштырылган, медицина ярдәме күрсәтүне, медицина эвакуациясен камилләштерү» ярдәмче программасы | 395 | 09 | 09 | 01 2 00 0000 0 | | 8 893 842,9 |
| Югары технологияле медицина ярдәмен камилләштерү, дәвалауның яңа нәтиҗәле алымнарын үстерү | 395 | 09 | 09 | 01 2 10 0000 0 | | 2 883 157,4 |
| Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминиятенең база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүгә финанслашу чыгымнары | 395 | 09 | 09 | 01 2 10 R402 0 | | 2 883 157,4 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка башка түләүләр | 395 | 09 | 09 | 01 2 10 R402 0 | 300 | 2 883 157,4 |
| Медицина оешмаларын мәҗбүри медицина иминияте системасы аша күбесенчә бер каналлы финанслауны гамәлгә ашыру (югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүдән тыш) | 395 | 09 | 09 | 01 2 12 0000 0 | | 6 010 685,5 |
| Медицина оешмаларын мәҗбүри медицина иминияте системасы аша күбесенчә бер каналлы финанслауны гамәлгә ашыру | 395 | 09 | 09 | 01 2 12 0519 0 | | 6 010 685,5 |
| Махсуслаштырылган медицина ярдәме, ашыгыч, шул исәптән ашыгыч махсуслаштырылган, медицина ярдәме күрсәтүне, медицина эвакуациясен мәҗбүри медицина иминияте системасы аша күбесенчә бер каналлы финанслауны гамәлгә ашыру | 395 | 09 | 09 | 01 2 12 0519 3 | | 4 199 898,0 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка башка түләүләр | 395 | 09 | 09 | 01 2 12 0519 3 | 300 | 4 199 898,0 |
| Медицина ярдәме күрсәтүнең мәҗбүри медицина иминияте база программасы белән билгеләнмәгән өстәмә төрләрен һәм шартларын финанс белән тәэмин итү | 395 | 09 | 09 | 01 2 12 0519 4 | | 1 810 787,5 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка башка түләүләр | 395 | 09 | 09 | 01 2 12 0519 4 | 300 | 1 810 787,5 |
| «Паллиатив ярдәм күрсәтү, шул исәптән балаларга» ярдәмче программасы | 395 | 09 | 09 | 01 6 00 0000 0 | | 358 766,6 |
| Паллиатив медицина ярдәме күрсәтү, шул исәптән балаларга | 395 | 09 | 09 | 01 6 01 0000 0 | | 358 766,6 |
| Паллиатив медицина ярдәме күрсәтүгә, шул исәптән балаларга, чыгымнар | 395 | 09 | 09 | 01 6 01 0202 0 | | 358 766,6 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка башка түләүләр | 395 | 09 | 09 | 01 6 01 0202 0 | 300 | 358 766,6 |
| Социаль сәясәт | 395 | 10 | 00 | | | 142 133,6 |
| Халыкны социаль тәэмин итү | 395 | 10 | 03 | | | 142 133,6 |
| «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасы | 395 | 10 | 03 | 03 0 00 0000 0 | | 142 133,6 |
| «Өлкән яшьтәге гражданнарның тормыш сыйфатын яхшырту» ярдәмче программасы | 395 | 10 | 03 | 03 2 00 0000 0 | | 142 133,6 |
| Өлкән яшьтәге гражданнарның социаль яклanышын ныгыту чараларын гамәлгә ашыру | 395 | 10 | 03 | 03 2 01 0000 0 | | 142 133,6 |
| Хезмәт ветераннарына социаль ярдәм чараларын тәэмин итү | 395 | 10 | 03 | 03 2 01 0521 0 | | 136 581,0 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка башка түләүләр | 395 | 10 | 03 | 03 2 01 0521 0 | 300 | 136 581,0 |
| Тыл хезмәтчәннәренә социаль ярдәм чараларын тәэмин итү | 395 | 10 | 03 | 03 2 01 0522 0 | | 45,1 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка башка түләүләр | 395 | 10 | 03 | 03 2 01 0522 0 | 300 | 45,1 |
| Реабилитацияләнгән затларга һәм сәяси репрессияләрдән зыян күргән дип танылган затларга социаль ярдәм чараларын тәэмин итү | 395 | 10 | 03 | 03 2 01 0531 0 | | 1 186,4 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка башка түләүләр | 395 | 10 | 03 | 03 2 01 0531 0 | 300 | 1 186,4 |
| Социаль ярдәмнең башка төрләрен күрсәтү | 395 | 10 | 03 | 03 2 01 0551 0 | | 4 321,1 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка башка түләүләр | 395 | 10 | 03 | 03 2 01 0551 0 | 300 | 4 321,1 |
| Чыгымнар, барлыгы | 395 | | | | | 72 148 109,2»; |

7) түбәндәге эчтәлекле 5 нче кушымта өстәргә:

«2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына

Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына 5 нче кушымта

2023 елга Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты кытлыгын эчке финанслау чыганаклары

(мең сумнарда)

| Россия Федерациясе бюджет классификациясе кодлары | Акчалар чыганагының исеме | Суммасы |
|---|---|---|
| 000 01 00 00 00 00 0000 000 | Бюджетлар кытлыкларын эчке финанслау чыганаклары | 1 676 536,8 |
| 000 01 05 00 00 00 0000 000 | Бюджетлар акчаларын исәпкә алу счетларында калган акчаларны үзгәртү | 1 676 536,8 |
| 395 01 05 02 01 09 0000 510 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларының калган башка акчалата чараларын арттыру | |
| 395 01 05 02 01 09 0000 610 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларының калган башка акчалата чараларын киметү | 1 676 536,8 |
| 000 01 06 00 00 00 0000 000 | Бюджетлар кытлыкларын эчке финанслауның башка чыганаклары | |
| 000 01 06 06 00 00 0000 000 | Бюджетлар кытлыкларын эчке финанслауның бүтән чыганаклары | |
| 395 01 06 06 00 00 0000 500 | Бюджетлар кытлыкларын финанслауның бүтән чыганакларын башка финанс активлары исәбеннән арттыру | |
| 395 01 06 06 00 09 0000 500 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары милкендәге башка финанс активларын арттыру | |
| 395 01 06 06 01 09 0000 510 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары милкендәге башка финанс активларын территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларының кредит оешмаларында Россия | |

| | | |
|---|---|---|
| | Федерациясе валютасында депозитларга урнаштырылган акчалары исәбеннән арттыру | |
| 395 01 06 06 00 00 0000 600 | Бюджетлар кытлыкларын финанслауның бүтән чыганакларын башка финанс активлары исәбеннән киметү | |
| 395 01 06 06 00 09 0000 600 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары милкендәге башка финанс активларын киметү | |
| 395 01 06 06 01 09 0000 610 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары милкендәге башка финанс активларын территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларының кредит оешмаларында Россия Федерациясе валютасында депозитларга урнаштырылган акчалары исәбеннән киметү | |

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**
**АҢЛАТМА ЯЗУЫ**

«2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды һәм Татарстан Республикасы бюджетларыннан бюджетара трансфертлар, башка салым керемнәре һәм салым булмаган керемнәр буенча кертемнәр күләмен тәгаенләүне исәпкә ала.

Закон проекты белән 2023 елга Фонд бюджетының керемнәр өлешендә түбәндәгеләрне арттыру күздә тотыла:

Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетыннан бюджетара трансфертларны – 143,5 млн.сумга;

Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертларны – 91,9 млн.сумга;

салым булмаган керемнәр өлешендә өстәмә кертемнәрне – 125,9 млн. сумга;

узган еллардан калган максатчан билгеләнештәге субсидияләрне, субвенцияләрне һәм башка бюджетара трансфертларны кире кайтаруны – 1,6 млн. сумга.

Моннан тыш, максатчан билгеләнештәге калган субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242 статьясындагы 5 пункт нигезендә бюджет системасы бюджетларына 490,3 млн.сум күләмендә кире кайтарылды, алар керемнәрдә «–» билгесе белән күрсәтелде.

Фонд бюджетының чыгымнар өлеше 1 549,2 млн.сумга арттырылды, шул исәптән:

«Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру системасын камилләштерү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыруга 1 357,8 млн.сум акча каралды, шулардан:

медицина оешмаларына табиблар һәм урта медицина персоналына хезмәт өчен түләүгә финанслашу чыгымнарына – 141,9 млн.сум;

халыкка диспансеризация һәм профилактик медицина тикшерүләрен уздыру барышында онкология авыруларын ачыклаган өчен медицина хезмәткәрләренә кызыксындыру характерындагы акчалата түләүләрне гамәлгә ашыруга – 1,6 млн.сум;

территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасына – 1 017,0 млн.сум;

медицина хезмәткәрләренә квалификация күтәрү программалары буенча өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру, шулай ук медицина җиһазлары сатып алу һәм ремонтлау чараларын финанс белән тәэмин итүгә – 154,7 млн.сум;

Россия Федерациясенең башка субъектлары территориясендә иминләштерелгән затларга Татарстан Республикасы медицина оешмалары

тарафыннан күрсәтелгән медицина ярдәмен финанс белән тәэмин итүгә – 42,6 млн.сум;

«Махсуслаштырылган, югары технологиялене дә кертеп, медицина ярдәме, ашыгыч, шул исәптән ашыгыч махсуслаштырылган, медицина ярдәме күрсәтүне, медицина эвакуациясен камилләштерү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыруга – 148,1 млн.сум;

«Паллиатив ярдәм күрсәтү, шул исәптән балаларга» ярдәмче программасына – 12,6 млн.сум;

«Өлкән яшьтәге гражданнарның тормыш сыйфатын яхшырту» ярдәмче программасына – 0,9 млн. сум;

Фондның идарә органнары эшчәнлегенең программаларга кертелмәгән юнәлешләренә – 29,8 млн.сум.

Кертелә торган үзгәрешләрне исәпкә алып, 2023 елга Фонд бюджеты керемнәре – 70 471,6 млн.сум, чыгымнары 72 148,1 млн.сум тәшкил итәчәк.

Бюджет кытлыгын эчке финанслау чыганагы булып Фонд счетында калган 1 676,5 млн. сум күләмендәге акчалар тора.

**«2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, гамәлләре туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яисә яңалары кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокук актлары**

## ИСЕМЛЕГЕ

«2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасының кайсы да булса законының һәм башка норматив хокук актларының үз көчен югалтуын тану, гамәлен туктатып тору, аларга үзгәрешләр кертү яисә яңаларын кабул итү таләп ителми.

**«2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты 2023 елга Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды (алга таба – Фонд) бюджеты керемнәрен 127 369,1 мең сумга, чыгымнарын 1 549 167,7 мең сумга арттыруны күздә тота.

2023 елга чыгымнарның керемнәрдән артып киткән өлеше (Фонд бюджеты кытлыгы) 1 676 536,8 мең сум тәшкил итәчәк. Фонд бюджеты кытлыгын эчке финанслау чыганагы булып калган акчалар үзгәреше тора.

2023 елга Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетының закон проекты белән каралган күрсәткечләре баланслана.